ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебяжье авыл җирлеге составына керүче Сакон Авылы торак пунктында

2019 елның 23 декабре № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге составына керүче Сакон торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда Лебяжье авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән, беренче төркем инвалидлар, көндезге уку студентлары, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:
- бистә эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту;
- торак пунктта урамнарны яктырту;
- Сакон авылының Үзәк урамы буенча балалар уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру

3. Әлеге карарны Лебяжье авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебяжье авылы, Үзәк урамы, 27А йорт, Сакон авылы, Үзәк урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Лебяжье авыл җирлеге башлыгы М.Б.Зверев